# ТӨБӘКЧЕЛЕК БЕЛЕМЕ ҺӘМ ТӨБӘК ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ («БУА ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ» МИСАЛЫНДА)

*Галиева Л. К.*

# LOCAL HISTORY AND REGIONAL ENCYCLOPEDIA (ON THE EXAMPLE OF THE «BUINSK ENCYCLOPEDIA»)

*Galieva L. K.*

Татар халык төбәкчелек белеме XIX гасырда – XX гасыр башында тарих фәне үсеше йогынтысында формалаша. Әлеге чорда авыллар һәм аерым бер җирлекләр тарихын төзегәндә шәҗәрәләр төп чыганакларның берсен тәшкил итә. К. Насыйри татарлардан беренчеләрдән булып Казан губернасындагы 20 авылның тарихы буенча фәнни-төбәкчелек әсәрен яза (1926 елда басыла). Татар телендә беренче тапкыр төбәк тарихы буенча нәшер ителгән хезмәт – җәмәгать һәм дин эшлеклесе, педагог, соңрак Россиянең 2 нче һәм 3 нче Дәүләт Думалары (1907–1912) депутаты М. М. Тукаевның (1862–1932) 1899 елда дөнья күргән «Тарихы Эстәрлебаш» китабы[1].

Совет чорында төбәкчелек белеменең чыганаклар базасы киңәя һәм төрләнә, чикле кысаларда булса да, архивлар фондларындагы төрле вакыйгаларга нисбәтле материаллардан файдалану мөмкинлекләре ачыла. Шул ук вакытта туган якны өйрәнү хәрәкәте идеологик-сәяси басым йогынтысында була. Әлеге күренеш Октябрь революциясеннән дистә еллар чамасы узганнан соң көчәя башлый. Биредә 1931 елда Коммунистик академиянең төбәкчеләр секциясе җирлегендә Төбәкче-марксистлар җәмгыяте оештырыла, IV Бөтенроссия төбәкчеләр конференциясендә төбәкчеләр оешмалар челтәрен үзгәртеп кору турындагы карар, 1937 елда РСФСР Халык Комиссарлары Советының «Төбәкчелек эшләрен үзәктә һәм урыннарда үзгәртеп кору турында» карары кабул ителү, соңгысында «төбәкчеләрнең Үзәк һәм җирле бюроларының алга таба яшәүләре максатка яраксыз» дип табылуы һәм Халык мәгарифе комиссариатына әлеге оешмаларны ябарга күрсәтмә бирелүе хәлиткеч роль уйный. Барлык өлкә җәмгыятьләре, шул исәптән Татарстанны өйрәнү җәмгыяте, Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте эшчәнлеге туктатыла, күп кенә күренекле төбәкче галимнәр эзәрлекләнә, зинданнарга ябыла, атыла. Әмма алга таба, псевдодемократик шигарьләр гамәлгә ашыры-

луы (моңа Бөек Ватан сугышының җиңүле тәмамлануы, Н.С. Хрущев «җепшеклеге» һ.б. этәргеч бирә) нәтиҗәсендә, тыюлар һәм чикләүләр дә үзгәрешләр кичерә, тик алар эчтәлекле мәйданны гына күздә тота, асыл («бердәм совет халкы тарихы уртак тамырларының тәкъдири бергәлеге») башлыча элеккегечә үк кала.

Әлбәттә, төбәкчелек белеме торышында сәяси-идеологик басым совет дәүләте үсешенең барлык чорларында да бер үк дәрәҗәдә саклана алмады, һәм ул җәмгыять торышының конкрет социологик халәтенә дә бәйле иде. Әлеге хакыйкать турыдан-туры милләтнең һәм аның билгеле бер территориядә гомер кичергән төркемнәренең, вәкилләренең иҗтимагый ихтыяҗлары эволюциясенә бәйле. Бу исә төбәкчелек белеменең оештыру формалары буенча дәүләт (ягъни фәнни), җәмәгать һәм мәктәп төркемнәренә бүленүендә ачык чагыла. Беренчесендә рәсми (дәүләти) мәнфәгатьләрнең өстенлек итүе табигый. Икенчесендә, рөхсәтле кысалар эчендә булса да, тарихи фикерләү, шәхси күзаллау һәм, билгеле бер дәрәҗәдә, мөстәкыйль тасвирлау омтылышы аңлашыла. Өченче төркемдә исә элгәреләрендәге принципларның синтезы күзәтелә, шул ук вакытта дәүләт идеологиясенең көчле йогынтысы саклана. Моны совет чорында мәктәпләрдә киң таралган колхоз-совхозлар, өлешчә генә булса да авыллар тарихын яктырткан альбомнар төзү хәрәкәте дә шаһитлый. Без боларны хәтерлибез.

Совет дәүләте таркалганнан соң (1991), милләтләр үзбилгеләнү хәрәкәтенең яңа өметләр яссылыгында яңаруы һәм җанлануы шартларында төбәкчелек белеме үзенең үсешендә тирән үзгәрешләр фасылына аяк баса. Бер яктан, төбәкнең (җөмләдән шундагы төп халыкның, торак пунктларның, хуҗалык итүче субъектларның) үткәненә карата игътибар кискен арта, икенче яктан, миллилек факторы көчәя – нәтиҗәдә өйрәнү объектына карата кызыксыну тирәнәя һәм тәфсилләнә төшә. Соңгы өч дистә ел эчендә эчтәлекләре нәкъ менә шул сыйфатта калыплашкан күп кенә басмалар дөнья күрде, алар арасында классик энциклопедия дәрәҗәсенә дәгъва иткәннәре дә шактый[2].

Төбәкчелек белеменең мәгълүматлары, һичшиксез, төбәк энциклопедияләренең фактик җирлегенә керә. Шул ук вакытта аларның үзара бәйсез формалашу үзенчәлекләрен дә инкарь итәргә нигез юк. Аерым алганда, 2010 елда дөнья күргән «Буа энциклопедиясе»[3] шулайрак төзелде. Хәер, әлеге төбәккә кагылышлы аерым хезмәтләр дә басылып чыкты[4].

«Буа энциклопедиясе»нең нәшер ителүе җәмәгатьчелектә мөһим вакыйга буларак кабул ителде. Шул ук вакытта ул республикабызда традицион фундаменталь энциклопедия кануннарына яраштырып эшләнгән тәүге басмаларның берсе иде. Әмма бу һич тә классик энциклопедияне турыдан-туры кабатлау түгел һәм алай була да алмый. Чөнки аларның һәрберсе алдына үзләренә генә хас таләпләр куела.

Әйтик, «Татар энциклопедиясе»ндә критерийлар милли кысаларда глобаль яссылыкны, ягъни дөньяда сибелеп яшәгән татар халкы һәм Татарстан Республикасы тарихында, икътисадында, мәдәниятендә мөһимлек югарылыгын күздә тотса, төбәк энциклопедиясендә исә критерийлар аерым бер төбәк дәрәҗәсен алга сөрә. Шуңа күрә район энциклопедиясендә мәгълүматларның тәфсиллерәк бирелүе дә, аларның гомуми энциклопедиядәгегә караганда күпкә киңрәк мәйдандагы объектларны һәм шәхесләрне колачлавы да табигый. Мисаллар китерик. Буа районына карата «Татар энциклопедиясе»ндә «Буа» (республика карамагындагы шәһәр), «Буа ветеринария техникумы», «Буа кантоны», «Буа медицина училищесе», «Буа өязе», «Буа өязе мөселманнары хәйрия җәмгыяте», «Буа районы», «Буа татар драма театры», «Буа төбәк тарихы музее», «Буа урман хуҗалыгы», «Буа шикәр заводы», «Буа» эше» мәкаләләре[5] һәм әлеге төбәктән чыккан күренекле эшлеклеләр хакындагы мәкаләләр урнаштырылган. «Буа энциклопедиясе»ндә исә без райондагы авыллар, учреждениеләр, гыйбадәтханәләр, шул исәптән район үзәгендәге оешмалар һәм предприятиеләр (алар басмада – биш дистәгә якын)[6], авыллардагы күренекле шәхесләр турындагы язмалар белән танышабыз. Биредә таләпләр бөтенләй башка. Шәхесләрнең глобаль үлчәмнәрдә мөһим тоелмаган казанышлары, алар лаек булган хөкүмәт бүләкләре һәм җирле бүләкләре, район үсешенә керткән өлешләре күрсәтелә. Шулай бәяләү бик урынлы һәм кирәк тә. Чөнки нинди һөнәр ияләре булуга карамастан аларның тарихта әһәмиятле үз эзләре бар, хезмәтләре ил иминлегенең нигезендә урын ала. Юкка гына Ватан төшенчәсе туган җирдән башлана, димиләр бит! Авылдашлар да, райондашлар да алар белән горурлана. Ватанпәрварлык шулай ярала һәм тәрбияләнә. Фундаменталь һәм төбәк энциклопедияләрнең үзара мөһимлек нисбәте мәсьәләсенә карата өстәп шуны ассызыкларга мөмкин: тасвирлау берәмлеге кечерәя барган саен игътибар объектлары зурая һәм күбәя бара, аларны яктырту да тирәнәя төшә. Бу исә төбәк энциклопедияләренең әһәмиятен бермә-бер көчәйтә. «Буа энциклопедиясе»нең якын арада яңа басмасы дөнья күрәчәк, шул рәвешле Татарстан төбәкчелек үсешендә яңа сәхифә ачылачак.

**Сведения об авторе:** Галиева Люция Камиловна, научный сотрудник Центра энциклопедистики Института татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ, e-mail: g.lyutzya@yandex.ru.

**Аннотация:** В статье рассматриваются некоторые особенности этапа развития краеведения в Республике Татарстан с начала 1990-х гг., значение краеведческих исследований в создании районных энциклопедий, соотношение татарской и региональной энциклопедии, специфика региональной энциклопедии на примере Буинского района Республики Татарстан.

**Ключевые слова:** краеведение, организационные формы краеведения, переформатирование содержания татарского краеведения, взаимосвязь краеведения и региональной энциклопедии, цели и специфика региональной энциклопедии.

**Abstract:** The article considers some features of the stage of development of local history in the Republic of Tatarstan since the beginning of the 1990s, the importance of local history research in the creation of encyclopedias of the districts of Tatarstan, the ratio of the Tatar and regional encyclopedias, the specifics of the regional encyclopedia on the example of the Buinsky district of the republic.

**Key words:** local history, organizational forms of local history, reformatting the content of Tatar local history, the relationship between local history and the regional encyclopedia, the goals and specifics of the regional encyclopedia.

БИБЛИОГРАФИЧЕСКИЙ СПИСОК

1 Татар энциклопедиясе: 6 томда / Баш мөхәррир М. Х. Сәлахов, җавап. мөхәррир Г. С. Сабирҗанов.– Казан: ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү ин-ты, 2019. Т. 6: Тә–Ч. Б. 87, 135.

2 Малахов В. С. Заинская энциклопедия.– Казань: Реноме, 1994. 268 с.; Из истории Альметьевского региона.– Альметьевск: НГДУ «Альметьевскнефть», 1999. Вып. 1. 351 с.; Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан.– Казань: Институт истории АН РТ, 1999. 366 с.; Сарман районы энциклопедиясе / Төз. Гарифуллин Д. Х.– Чаллы, 2000. 286 б.; Балтач энциклопедиясе. 2 нче кит. / Төз. Мөхәммәтшин Г. С.– Казан, 2010. 531 б.; Апастовская историко-краеведческая энциклопедия / Сост. Сункишев А. Г.: Т. 1.– Казань: Респ. Центр мониторинга качества образования, 2013. 231 с., Т. 2.– Казань: Школа, 2014. 228 с., Т. 3.– Казань: Школа, 2014. 239 с.; Энциклопедия города Булгар и Спасского района.– Казань, 2014. 517 с.; Дрожжановская энциклопедия / Сост. Закиров И. Р.– Чебоксары: Перфектум, 2020. 620 с.

3 Буинская энциклопедия.– Казань, 2010. 391 с.

4 Буа ягым – Тау ягым = Буинские просторы.– Казань, 2000. 447 с.; Салихов Р. Р., Хайрутдинов Р. Р. Из истории населенных пунктов Буинского района Республики Татарстан.– Казань: Институт истории АН РТ, 2002. 108 с.; Хәлиуллин И. Х. Яңа Тинчәле таңы.– Казан, 2006. 224 б.; Язмышым минем – Норлат / Төз. Әхмәтҗанов И. Г., Хәлиуллин И. Х.– Казан, 2009. 272 б.; Зыятдинов Р. Ш., Зыятдинов К. Ш., Хәлиуллин И. Х. Әлки ядкәре.– Казан, 2010. 223 б.

5 Татар энциклопедиясе: 6 томда / Баш мөхәррир М. Х. Хәсәнов, җавап. мөхәррир Г. С. Сабирҗанов.– Казан: ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү ин-ты, 2008. Т. 1: А–В. Б. 592–595.

6 Буинская энциклопедия.– Казань, 2010. С. 83–90.